**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**КАРАР №10**

III чакырылыш чираттан тыш утырышы Урыссу ш.т.п. 17 март 2020 ел

**“Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында” карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2015 елның 11 сентябрендәге 43 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ :

1. №1 кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проектын кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 9 апрелендә, 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.

Гавами тыңлауларны Татарстан Республикасы Ютазы район Советы бинасында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Урыссу ш. т. п., Пушкин ур., 38 йорт, 2 кат, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының утырышлар залы.

3. Халык алдында тыңлаулар турында гражданнарга мәгълүмат бирү тәртибе ачык тыңлаулар материаллары белән алдан танышуны үз эченә ала: Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставын кабул итү турында" карар проекты белән “Ютазы таңы” ("Ютазинская новь") газетасында рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталына урнаштыру юлы белән танышуны .

4. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында" карар проекты буенча ачык фикер алышулар уздырылуы турында хәбәрне

гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») газетасында рәсми бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы порталына урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru/

5. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютазинская нов») газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), әулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/.адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Ютазы**
**муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **З.М. Әгълиева**